# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 21 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

«Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына (2010 елның 5 июлендәге 51-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 11; 2004, № 3 (I өлеш), № 4 – 5, № 10, № 11; 2005, № 7 – 8, № 11; 2006, № 2 (I өлеш), № 4, № 11 (I өлеш); 2007, № 7 (II өлеш); 2008, № 5 (I өлеш), № 7 (I өлеш); 2009, № 6, № 11; 2010, № 7 (II өлеш); 2011, № 5, № 8 (I өлеш); 2012, № 2, № 6 (I өлеш), түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«2 статья. **Салым ставкалары**

1. Салым ставкасы, әлеге статьяның 2 өлешендә башкача каралмаган булса, 2,2 процент күләмендә билгеләнә.
2. Гомуми файдаланудагы тимер юлларга, магистраль торбаүткәргечләргә, электр тапшыруы линияләренә, шулай ук күрсәтелгән объектларның аерылгысыз технологик өлеше булып торган корылмаларга карата салым ставкалары 2013 елда – 0,4 процент, 2014 елда – 0,7 процент, 2015 елда – 1,0 процент, 2016 елда – 1,3 процент, 2017 елда – 1,6 процент, 2018 елда 1,9 процент күләмендә билгеләнә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң бер ай узгач үз көченә керә һәм 2013 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2013 елның 11 марты
№ 19-ТРЗ